**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Югары Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә авылы, Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында

**27 октябрь 2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә авылы, Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын ремонтлау һәм буяу, скважиналар павильоннарының стеналарын тышлау һәм идәнен бетонлау, эчәргә яраклы суга анализ ясау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу, Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр авыллары торак пунктларында насослар сатып алу);
- каты коммуналь калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын норматив хәлгә китерү, каты көнкүреш калдыкларын оештыру һәм чыгару, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- зиратны төзекләндерү, агач кисү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктлары территорияләрендә дератизация чаралары үткәрү өчен түләү;
- авыл җирлегенең урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерүгә вак таш (щебенка) җәю, зиратларга керү юлларын, зиратларның керү мәйданчыгын да

кертеп;

- «Таллы Чишмә» чишмәсен ремонтлау (чишмә территориясенең санитар-яклау зонасын төзекләндерү, санитар саклау зонасының беренче поясына коймалар кую, павильонны ремонтлау, павильон тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, елга үзәнен чистарту, Югары Кәминкә торак пунктында грунт (ил) чыгару, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу, югары кәүсәле агачларны кисү, ПСД әзерләү өчен түләү;

- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү буенча проект-смета документлары өчен түләү;

- санитар саклау зонасы проектын эшләү өчен түләү, Югары Кәминкә авылы артезиан скважинасының санитар саклау зонасының беренче поясын («Салкын Чишмә») киртәләп алу, киртә җайланмасы ПСД әзерләү өчен түләү;

- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, агач һәм куакларны җыештыру, күперләрне һәм җәяүлеләр кичү юлларын ремонтлау, йорт һәм урамнар номерларын һәм табличкаларын сатып алу, юл-урам челтәренең юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кыш көне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр, запас частьләр өчен түләү) Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, смета документлары проектларын әзерләү өчен түләү. Инструментлар сатып алу (2 шт. бензопила, 2 шт. триммер чапкыч, һәм кирәкле материаллар);

- «Керкәле» чишмәсен ремонтлау (чишмә территориясенең санитар-яклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, павильон урнаштыру, павильон тышлау, каты өслекле юл урнаштыру, елга үзәнен тирәнәйтү, грунт (ил) чыгару, иске агачларны һәм куакларны кисү һәм җыештыру Ибрай Каргалы торак пунктында, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, ПСД әзерләү өчен түләү.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы М.Н.Минһаҗев